


# Татарстан Республикасы

# Нурлат муниципаль районы

# Колбай Мораса урта гомуми белем мәктәбенең

# 2017-2018 нче уку елына

# укыту – тәрбия эшләре планы

План 2017 нче елның 29нчы август №1 педсовет утырышында кабул ителде.

Беркетмә №56, 29 нчы август 2017 нчы ел

**Эчтәлек.**

**I 2015 -2016 нчы уку елында укыту-тәрбия эшчәнлегенә анализ...3 бит.**

1. Укыту-тәрбия эшчәнлегенә анализ.......…...............................................3 бит.

2. Методик эшчәнлеккә анализ...........………….......................................10 бит.

3. Эчке контрольгә анализ..........……………........................................... 12 бит.

4.Тәрбия эшчәнлегенә анализ........…………….............................................14 бит.

5.Укучыларны сәламәтләндерү эшчәнлегенә анализ..................................17 бит.

6. Мәктәп китапханәсе эшчәнлегенә анализ...........…..................................18 бит.

7. Материаль-техник базаны ныгыту эшенә анализ.........……………….. 18бит.

**II 2017 -2018 нче уку елына укыту-тәрбия бурычлары................ 19 бит.**

**III 2017 -2018 нче уку елына укыту-тәрбия планы.......................19 бит.**

- Август-сентябрь айларына эш планы.........................................................19 бит.

- Октябрь аена эш планы...............................................................................24 бит.

- Ноябрь аена эш планы.................................................................................28 бит.

- Декабрь аена эш планы...............................................................................32 бит.

- Январь аена эш планы.................................................................................35 бит.

- Февраль аена эш планы...............................................................................38 бит.

- Март аена эш планы.....................................................................................41 бит.

- Апрель аена эш планы..................................................................................44 бит.

- Май-июнь айларына эш планы....................................................................47 бит.

**IV 2017 -2018 нче уку елына эчке контроль планы ......................51** бит.

- “Мәгариф турында” РФ һәм ТР законнарының үтәлеше.........................51 бит

- санитария-гигиена режимы, техника куркынычсызлыгы үтәлеше...........52 бит.

- укыту-тәрбия процессы..................................................................................54 бит.

- мәктәп документациясе..................................................................................56 бит.

-балаларның белем алуга хокукын гамәлгә ашыру,матди тәэмин итү һәм

Финанслау..........................................................................................................59 бит

-китапханәнең еллык эш планы........................................................................62 бит.

## I. 2016 -2017 нчы уку елында укыту-тәрбия эшчәнлегенә анализ.

Узган уку елында педагогик коллектив эшчәнлекне еллык укыту-тәрбия планы нигезендә, түбәндәге бурычларны тормышка ашыру буенча оештырды:

1. Балаларның белем алуга хокукын гамәлгә ашыру, гомуми урта белем алу мөмкинлеге булдыру һәм белем бирүне аның сыйфатын күтәрергә ярдәм итәрлек яңа технологияләр кулланып оештыру;

2. Профильле укыту кысаларында белем бирүне укучының шәхси ихтыяҗларын, кызыксынуларын һәм мөмкинлекләрен исәпкә алып оештыру;

3. “Дәрестән соң мәктәп” дәүләт мәгариф инициативасын гамәлгә ашыру максатыннан Федераль дәүләт стандартларын куллануны гамәлгә кертү.

4. Бердәм дәүләт имтиханнарына әзерлекне яхшырту максатыннан, комплексы чаралар оештыру, фәннәрне начар үзләштерүчеләрне имтиханнарга әзерләү буенча эшчәнлекне яхшырту;

5. Реаль ихтыяҗларны һәм белем бирүне модернизацияләү бурычларын истә тотып, мәктәпне заманча интерактив уку әсбаплары, китапханә фондын сыйфатлы дәреслекләр, әдәби әсәрләр, белешмә материаллар, төрле тармакка караган фәнни әдәбият белән тәэмин итү;

6. Сәләтле укучылар белән эшчәнлекне төрле формаларда оештыру, педагогик коллективны һәм укучыларны төрле конкурсларда катнашырга мотивлаштыру;

7. Укучылар арасында тәртип бозуларны, белем алуга карашларын уңай якка үзгәртү максатында, эти-әниләр белән эшчәнлекне көчәйтү; сәламәт яшәү рәвешен пропагандалау; граҗданлык активлыгын үстерү.

«Мәгариф турында» ТР законының балаларның белем алуга хокукын тәэмин итү турындагы статьясында күрсәтелгән бурычлар үтәлде. Ел дәвамында укуын ташлаучы, икенче елга классында кабат калучы укучылар булмады. Узган уку елын 86 укучы белән башлап, 86 укучы белән тәмамладык.

9 сыйныфны 7 укучы тәмамлады. 4 укучы 10 нчы сыйныфка калдылар, 5 укучы колледжларга китте.

11 нче сыйныфны 13 укучы тәмамлады. Шуларның 6 сы ВУЗга (КФУ), 4се мед. техникумга, 1се педтехникумга, 2се техникум легкой промышленности укырга керделәр.

Узган уку елында 1 нче сыйныф укучылары 5 көнлек, калган барлык класслар да 6 көнлек эш режимында эшләде. Укучылар 12 уку кабинеты, 1 спорт залы, 1 китапханә бүлмәсендә шөгыльләнде. Үзебезнең җирлектә яшәгән барлык балалар да укуга тартылды һәм аларның дәрескә йөреше һәркөн системалы рәвештә контрольгә алынды, нәтиҗәләр ясалды.

Мәктәпнең укыту планы Татарстан Мәгариф һәм Фән министрлыгы раслаган региональ базис укыту планы нигезендә төзелде. Программа материалы барлык фәннәрдән дә үтелеп бетте. Укучыларга һәр фәннең үз стандартыннан чыгып белем бирелде. Өлгермәүче һәм сыйныфтан сыйныфка күчми калган укучылар булмады.

Башлангычның 4 сыйныфында 24 (филиалда-6) , урта звеноның 5 сыйныфында 34 укучы , өлкән сыйныфларда-28 укучы , барлыгы-86 укучы уку елын тәмамлады.

. Узган уку елы нәтиҗәләре буенча мәктәптә белем сыйфаты 64%. Еллык билгеләр буенча «5» кә генә тәмамлаучы 12 укучы, «4-5» кә 40укучы, калганы “4”һәм “3” генә уку елын тәмамлады. 1 нче сыйныф укучыларына билге куелмый.

**МӘКТӘПНЕҢ 5 ЕЛДА ӨЛГЕРЕШ ҺӘМ СЫЙФАТ КҮРСӘТКЕЧЛӘРЕНӘ АНАЛИЗ.**

| Уку елы | өлгереш % | | | Сыйфат % | | | Гомуми (мәктәп буенча) % |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | 1-4 | 5-9 | 10-11 | 1-4 | 5-9 | 10-11 | |
| 2011-2012 | 95 | 97 | 100 | 50 | 40 | 63 | 48 |
| 2012-2013 | 94 | 98 | 100 | 52 | 42 | 57 | 47 |
| 2013-2014 | 92 | 100 | 100 | 46 | 52 | 58 | 48 |
| 2014-2015 | 93 | 100 | 100 | 53 | 56 | 76 | 63 |
| 2015-2016 | 100 | 100 | 100 | 50 | 59 | 72 | 60 |
| 2016-2017 | 100 | 100 | 100 | 52 | 64 | 71 | 64 |

**Аерым фәннәр буенча белем сыйфаты түбәндәгечә булды (%):**

| № | Фәннәр | 2015-2016 | 2016-2017 |
|---|---|---|---|
| 1 | Татар теле | 75 | 71 |
| 2 | Әдәбият | 81 | 85 |
| 3 | Рус теле | 60 | 65 |
| 4 | Литература | 76 | 88 |
| 5 | Инглиз теле | 70 | 79 |
| 6 | Математика | 69 | 75 |
| 7 | Физика | 62 | 75 |
| 8 | Химия | 56 | 78 |
| 9 | Биология | 68 | 78 |
| 10 | Информатика | 77 | 84 |
| 11 | География | 83 | 80 |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 12 | Тарих | 68 | 70 |
| 13 | Җәмгыять белеме | 69 | 71 |
| 14 | Физкультура | 100 | 100 |
| 15 | ТИН | 100 | 100 |
| 16 | Табигать белеме | 64 | 83 |
| 17 | Технология | 100 | 100 |
| 18 | Музыка | 100 | 100 |
| 19 | Сынлы сәнгать | 100 | 100 |
| 20 | Литературное чтение | 80 | 83 |
| 21 | Литературное чтение (тат) | 90 | 94 |

**Һәр сыйныфта укучыларның белем дәрәҗәсенә күз салсак, нәтиҗәләр түбәндәгечә:**

| Класс | Уку елы ахырында укучы саны | «5»кә генә | Бер генә «4»ле | «4-5»кә | Бер генә «3» ле | «3-4»кә | «2»гә | Белем сыйфаты (%) |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 2 | 3 | | | 2 | | | | 66 |
| 3 | 3 | | | 1 | | | | 33 |
| 4 | 13 | | | 7 | | | | 50 |
| 5 | 2 | 1 | | 1 | | | | 100 |
| 6 | 7 | 2 | | 2 | | | | 57 |
| 7 | 4 | | | 2 | | | | 50 |
| 8 | 12 | 2 | | 5 | | | | 58 |
| 9 | 7 | 1 | | 6 | | | | 100 |
| 10 | 15 | 3 | | 6 | | | | 53 |
| 11 | 13 | 3 | | 7 | | | | 76 |

## НӘТИҖӘЛӘР:

Өлгереш стабильләште- 100%, сыйфат 64 %ка менде. Узга уку елында 3 звенода да сыйфат бертөрле, бу укучылар күчеш чорында зур киртәләргә очрамыйлар, укуның һәр баскычында белем бирү сыфаты тигез дип уйларга җирлек бирә.

Иң түбән сыйфат күрсәткечен 3 нче сыйныфлар бирде 33%. Барлык сыйныфларда да белемне бирүгә һәм кабул итеп алуга таләпләрне арттырырга кирәк, бигрәк тә 3 сыйныфны бетергән укчылар белән эшне көчәйтергә.

**БДИ нәтиҗәләренә чагыштырмача анализ.**

| Код предмета | Предметы | 2013 | 2013 ОУ | 2013 | 2014 | 2014 | 2014 | 2015 район | 2015 ОУ | 2015 | 2016 район | 2016 ОУ | 2016 | 2017 |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|

| | | район | | РТ | район | ОУ | РТ | | | РТ | | | РТ | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Рус теле | 68.1 | 62 | 67.3 | 60.3 | 52 | 65.8 | 64.1 | 59,2 | 69.2 | 71.3 | 63.13 | | 66 |
| | | | | | | | | | | | | | | |
| 22 | Математика (баз.) | - | | - | - | | - | 4.01 | 3.8 | 4 | 4.34 | 4.3 | 4.33 | 4,15 |
| 2 | Математика (проф.) | 65.2 | 61 | 56.1 | 41.1 | 35 | 48.6 | 49.4 | 38 | 50.1 | 52.8 | 42.6 | 52.08 | 35,8 |
| 3 | Физика | 55.4 | 34 | - | 41.7 | 33 | 47.7 | 52 | 48 | 54.6 | 48.9 | 43 | - | 53 |
| 4 | Химия | 81 | - | - | 59.5 | 47 | 62.5 | 66.8 | 46 | 63.4 | 56.8 | - | - | |
| 6 | Биология | 70.3 | 54 | 65.8 | 53.6 | 52 | 58.8 | 60.6 | 62 | 58.9 | 58.68 | - | 58.76 | 50,5 |
| 7 | Россия тарихы | 72.3 | - | 62.9 | 50.5 | - | 50.1 | 54.1 | 64 | 53.3 | 48.27 | - | 53.75 | |
| 12 | Җәмгыять белеме | 65.2 | 58 | | 53.5 | 51 | 55.9 | 57.6 | 52 | 55.6 | 56.3 | 44 | 57.27 | 55.2 |
| 5 | Информатика | 76.8 | - | 71.1 | 50 | - | 60.7 | 53.6 | - | 59.5 | 37 | - | 63.96 | 59 |
| 8 | География | 61 | - | 66 | 73.6 | - | 64.4 | 75 | - | 67.3 | 64.3 | - | 69.86 | |
| 18 | Литература | 62.4 | - | - | 49.3 | - | 52.8 | 60.3 | - | 57.8 | 59.2 | - | 58.06 | |
| 9 | Инглиз теле | 68.1 | - | - | 45.6 | - | 66 | 66.4 | - | 72.7 | 68.11 | - | 74.88 | |

Имтиханнарга әзерлек план нигезендә алып барылды, математикага да, рус теленә дә мәктәп компонентыннан өстәмә дәресләр,электив курслар бирелде, администрация тарафыннан укучылар һәм әти-әниләр белән даими рәвештә җыелышлар үткәрелде, аңлату эшләре алып барылды, имтихан тестлары буенча административ контроль эшләр үткәрелде. Укучылар интернет челтәрендәге һәр яңалыкны консультацияләр вакытында кулландылар. СТАТГРАД, Решу ЕГЭ һәм башка сайтлар үткәргән диагностик тестларда катнашып, имтиханнарга әзерлек дәрәҗәсен билгеләп, хаталар өстендә эшләделәр. 9,11 классукучылары өчен үткәрелгән он-лайн тестированиеда катнаштылар. Кышкы каникулда математика һәм рус теленнән, язгы каникулда барлык фәннәрдән сынау имтиханнары үткәрелеп, анализ ясалды. Фән укытучылары да, укучылар да, әти-әниләр дә имтиханнарга җаваплы карадылар. БДИны укучының уңышлы тапшыруына ирешү өчен, фән укытучысы, класс җитәкчесе, әти-әниләрнең бердәм эшчәнлеге кирәк. Барыбыз да бердәм эшләгәч, нәтиҗәләр дә куанычлы булды. Бер фәннән дә минималь балл җыя алмаган, аттестат тапшырылмаган укучы булмады

БДИ нәтиҗәләренә күз салсак барлык фәннәрдән дә күрсәткечләр районныкыннан кимрәк.. Барлык фәннәрдән дә нәтиҗәләр алдагы еглдагыдан яначаррак. Димәк,әле барлык фәннәрдән дә имтиханнарга әзерлекне арттырырга һәм район нәтиҗәләре югарылыгына җиткерергә кирәк.

**9 нчы СЫЙНЫФТА ИМТИХАН НӘТИҖӘЛӘРЕ.**

2017 нчы елда гомуми төп белем бирү пргграммаларын үзләштергән чыгарылыш класс укучыларына яңа формада дәүләт йомгаклау аттестациясе үткәрү 11 предмет буенча дәвам итте: рус теле, математика, Россия тарихы, физика, география, инглиз теле,

җәмгыять белеме, химия, биология, рус әдәбияты, информатика. Татар теленнән апробация формасында икенче тапкыр имтиханнар яңа формада үткәрелде.

Мәҗбүри һәм сайлап алу предметлары буенча имтиханнар Татарстан Республикасының Дәүләт имтихан комиссиясе катнашында үтте.

Мәҗбүри ике имтиханда 9 классны тәмамлаган 18 укучының 18е да катнашты.

Яңа формада үткәрелгән имтихан нәтиҗәләре:

9 нчы классны тәмамлаучылар да дәүләт йомгаклау аттестациясен төп дәүләт имтиханы (ОГЭ) формасында үтте. 18 укучы да имтиханга кертелде.Ул 28 майдан 17 июньгә кадәр дәвам итте. Рус теле һәм математикадан ОГЭ , татар теленнән бердәм республика тесты тапшырдылар. Сайлап алу фәннәреннән 4 укучы җәмгыять белеме,географиядән -13 укучы биологиядән 16 укучы ,информатикадан-3 укучы имтихан тапшырды. Нәтиҗәләр түбәндәгечә булды:

| Фән | Барлык укучы | «5» | «4» | «3» | «2» | Уртача билге | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | мәктәп | район | РТ |
| Математика | 7 | 1 | 5 | 1 | 0 | 4 | 3.7 | 3.87 |
| Рус теле | 7 | 0 | 5 | 3 | 0 | 3.7 | 3.8 | 4.09 |
| Татар теле | 7 | | | | | 34.14 | | |
| Биология | 1 | | 1 | | | 4 | 3.2 | 3.43 |
| Информатика | 6 | | 4 | 2 | | 3.6 | 3.5 | 3.72 |
| География | | | | | | 3 | 3.4 | 3.49 |
| Җәмгыять белеме | 7 | | 2 | 5 | | 3,1 | 3.23 | 3.40 |

**9 нчы сыйныфларның еллык белем сыйфаты**

| № | Предмет | Уку сыйфаты, % |
|---|---|---|
| 1 | Татар теле | 71 |
| 2 | Әдәбият | 71 |
| 3 | Рус теле | 71 |
| 4 | Литература | 71 |
| | | 71 |
| 5 | Инглиз теле | 71 |
| 6 | Математика | 71 |
| 7 | Физика | 71 |
| 8 | Химия | 71 |
| 9 | Биология | 71 |
| 10 | Информатика | 71 |
| 11 | География | 71 |
| 12 | Тарих | 71 |
| 13 | Җәмгыять белеме | 71 |
| 14 | Физкультура | 100 |
| 15 | искусство | 100 |

Имтихан нәтиҗәләре начар булмады. Яхшы күрсәткеч биология , математика фәннэреннэн . Еллык билгеләр буенча 9 нчы сыйныфларның белем сыйфаты да начар түгел. Шуңа күрә әлеге фән укытучыларына имтиханнарга әзерләүнең яңа формаларын эзләргә, эшчәнлекне яхшы нәтиҗәгә ирешерлек итеп оештырырга кирәк.. 9 нчы сыйныфларның имтихан нәтиҗәләре, тулаем алганда, бик начар түгел. Бу уку елында һәр укытучыдан, бигрәк тә чыгарылыш классларында эшләүчеләрдән, укучыларның белемнәренә булган таләпләрне тагын да арттыру, белемнәрне бәяләү критерийларын кабат карау һәм имтиханнарга ныклап әзерләнү сорала. Югыйсә укучыларыбызның 9 нчы сыйныфны да аттестатсыз тәмамлавы мөмкин.

**Укуга сәләтле укучылар белән эш нәтиҗәләре.**

Укучыларның уку сыйфаты ел саен олимпиада нәтиҗәләрендә күренә. 2016-2017 нче уку елында 10 октябрьдән 27 октябрьгә кадәр мәктәптә 23 фәннән олимпиадаларның мәктәп турлары үткәрелде, нәтиҗәләр чыгарылды. 2016 нче елның 14 ноябреннән 16 декабрьгә кадәр бөтенрәсәй һәм республика олимпиадаларының муниципаль этабы булды. I турда җиңүчеләр олимпиадаларның район турларында катнаштылар, әмма бер призлы урын да булмады. Бу укытучыларның сәләтле укучылар белән эшне дөрес итеп тиешенчә оештырмауларын күрсәтә. **Узган** уку елында октябрьдә мәктәптә фән олимпиадаларының сайлап алу турлары үткәрелде, нәтиҗәләр чыгарылды.I турда җиңүчеләр олимпиадаларның район турларында катнаштылар.11 нчы сыйныф укучысы Ильина Ирина татар теле фәненнән районда җиңүче булды һәм район һәм мәктәп данын яклап, Казанга республика олимпиадасына барды.Татар теленнән Матвеева Маша, Загртдинова Рәмзия-10 сыйныф, Галиуллина Руфинә-6 сыйныф,Гайнетдинова Руфинә-5сыйныф,Минапова Фирузә-8 сыйныфтан районда призер булдылар.

Олимпиада нәтиҗәләре сәләтле укучылар белән эшчәнлекнең төп күрсәткече булып торганлыктан, бу юнәлештә эшне кечкенә сыйныфлардан ук көчәйтергә.Сәләтле укучылар белән иртәгә олимпиада буласы көнне генә шөгыльләнеп, уңышка ирешеп булмаячагы көн кебек ачык. Бары тик алар белән даими шөгыльләнергә һәм теория буенча белемнәрен ныгытырга кирәк.

**Конкурслар:**

Ел саен безнең укучыларыбыз республика масштабында төрле конкурсларда катнашалар.

Мәсәлән, “Алтын каләм” конкурсында 3 ел рәттән призлы урыннар, Лобачевский исемендәге конференөиядә уңышлы чыгыш ясау, «НПК «Бер жирдә юк, бездә генә»-2,3 урыннар,

« России династияләре»- призлы урыннар , «Эрудит России»-призлы урыннар, Татар теленнән халыкара олимпиада – читтән торып катнашу, «Син Тукайны беләсеңме?»- җиңүчеләр, “Зәңгәр ягулык җылысы” конкурсы- 3 ел рәттән җиңүчеләр. Учи.ру.конкурсы һ.б.

**Гомуми нәтиҗә.**

1. 2016-2017 нчы уку елына куелган бурычлар тулысынча үтәлеп бетмәде дип әйтеп була. Уку программалары һәр фәннән дә үтәлде. Укучыларның мәктәптә үткәрелә торган иҗади

эшләрдә активлыклары артты. Әмма төрле конкурсларда һәм конференцияләрдә катнашуны арттырырга. Төп урта мәктәп укучыларның имтихан нәтиҗәләре буенча хәзерлеге канәгатьләнерлек, БДИ, ДЙА нәтиҗәләре начар түгел.

**2.** Куелган бурычлар өлешчә генә үтәлде.

3. Уңай нәтиҗәләр белән кимчелекләр дә юк түгел:
Укуга сәләтле балалар белән эш җитәрлек дәрәҗәдә бармый
( олимпиадалар)
Заман технологияләрнең күбрәк кулланырга ( информацион-коммуникатив)
Имтиханнарга хәзерлек эшен тиешле югарылыкта алып барырга
Укучылар һәм укытучылар эшчәнлеген мониторинг үткәрүне җайга салырга.
Интернетта булган конкурсларда активрак катнашырга.

## Методик эшчәнлеккә анализ

Укытучыларның педагогик осталыкларын күтәрүнең мөһим чарасы булып, мәктәп эшен системага салучы булып, методик эш тора. Хәзерге заман шартларында һәм тәрбия алымнарын, яңа методикаларны рациональ һәм оператив куллануда мәктәптә методик эшнең роле тагын да арта.

Мәктәп 2016-2017 нчы уку елына кадәр "Дәресләрдә һәм класстан тыш чараларда әхлак тәрбиясе биру, сәләтле балалар белән эш алымнарын камилләштерү." темасы астында эшләде..

1. Укытуның сыйфатын күтәрү буенча эшчәнлекне дәвам итәргә.
2. Укыту процессына яңа укыту технологияләрен кертергә.
3. Укучыларны БДИга әзерләү максатыннан, кечкенә класслардан ук контрольне тест формасында үткәрергә.
4. Укучыларны фәнни-тикшеренү, проект эшчәнлегенә тартырга һәм фәнни-практик конференцияләрдә, конкурсларда актив катнашырга.
5. Белем алырга сәләтле укучылар белән эшчәнлекне арттырырга, аларның фән олимпиадаларында, интеллектуаль марафоннарда катнашуын тәэмин итәргә.
6. Педагогик совет эшчәнлегенең яңа форма һәм методларын эзләргә.
7. Мәктәпнең материаль-техник базасын ныгыту буенча эшне дәвам итәргә.

Куелган бурыч һәм максатлардан чыгып, методик эшчәнлек түбәндәге юнәлешләрдә оештырылды:
- мәктәптә методик эшчәнлекнең иң югары формасы буларак, педагогик совет утырышлары;
- методик совет эшчәнлеге;
- укытучыларның квалификациясен һәм осталыгын күтәрү;
- эшкә кабат килгән һәм яшь специалистлар белән консультатив- информацион эшчәнлек;
- иҗади эшләүче методик берләшмәләр эшчәнлеге;
- индивидуаль-методик һәм инновацион эшчәнлек – алдынгы тәҗрибә уртаклашу;
- аналитик-диагностик эшчәнлек, психологик-педагогик диагностика;
- кабинетларның методик җаһазланышын яңарту.

Узган уку елында, планда каралганча, 5 педагогик совет утырышы түбәндәге темалар буенча уздырылды:

1. .“Дәрестән соң мәктәп” дәүләт мәгариф инициативасын гамәлгә ашыру максатыннан мәктәп эшчәнлеген оештыру.
2. “Исән укучы тәрбияләү”.
3. “Укытучының һөнәри абруе”.
4. “Коммуникация һәм хезмәттәшлек күнекмәләрен арттыру”.
5. - Укучыларны сыйныфтан сыйныфка күчерү.

- Чыгарылыш сыйныф укучыларын имтиханнарга кертү.
- Чыгарылыш сыйныф укучыларына аттестатлар тапшыру.

Педсоветларның барысы да алдан әзерлек белән, куелган бурычлардан чыгып үткәрелде. Педсоветларда ”Дәрестән соң мәктәп ” дәүләт мәгарифе инициативасының төп юнәлешләре”, “Яңа стандартларны гамәлгә ашыруда төп проблемалар, аларны тормышка ашыру юллары”, “Укучыларда креатив фикерләү формалаштыру”, “Укытучының профессиональ осталыгын күтәрү юллары”, “Мультимедиа технологиялэренең укыту сыйфатын күтәрүдәге роле” темаларынга эшлекле чыгышлар тыңланды. Галиуллина Р.Г.,Бурганова Г.Г, Валеева Л.А.үз чыгышларында педсоветка куелган мәсьәләләрне киң яктырттылар.

Педсоветларда чирек, яртыеллык нәтиҗәләре, педагогик коллектив эшчәнлеге, укучылардан алынган анкеталар анализланды, алга куелган бурычларны үтәү юллары эзләнде. Электрон журнал һәм электрон көндәлекләр белән эшләү күнекмәләре булдырылды. Фикер алышулар вакытында коллективның һаман да шул бер төркеме генә катнашуы, яшь укытучыларның укыту-тәрбия процессына битарафлыгы күзгә ташланды.

5 кешелек составтан торган методик совет белән укыту эшләре буенча директор урынбасары җитәкчелек итте. Методик совет утырышларында түбәндәге мәсьәләләр каралды:

- 2016-2017 нчы уку елында методик эшчәнлеккә анализ, яңа уку елына эш планлаштыру;

- тематик педсоветларга әзерлек;
- 1, 5, 10 класс укучыларының адаптация чорын өйрәнү;
- олимпиадаларның мәктәп турларын әзерләү һәм үткәрү;
- олимпиадаларның район турлары нәтиҗәләре;
- эчке контроль планы буенча контроль эшләр үткәрү, аларны анализлау;
- фән атналыкларына әзерлек;
- укучыларны фәнни-тикшеренү эшенә тарту буенча эшчәнлек;
- укытучыларны аттестациягә әзерләү;
- имтиханнарга әзерлек, имтихан материаллары әзерләү;
- 2016-2017 нчы уку елы йомгаклары, яңа уку елына әзерлек;
- 2016-2017 нчы уку елына план төзү.

Укытучылар тарафыннан, тәҗрибә уртаклашу максатында, мәктәп күләмендә һәм район семинарларында ачык дәресләр, дәрестән тыш чаралар күрсәтелде. Ләкин ачык дәрес һәм чаралар күрсәтү, үзара дәресләргә керү җитәрлек дәрәҗәдә булмады. Укытучылар төрле конкурсларда актив катнаштылар һәм матур нәтиҗәләргә ирештеләр.

2016-2017 нчы уку елында методик совет каршында 5 методик берләшмә үз юнәлешләре буенча эшчәнлек оештырды. Һәр берләшмә үз алдына укытучыларның һөнәри осталыгын үстерү; укучыларның кызыксынулары, сәләтләре һәм мөмкинлекләрен ачыклап, төрле интеллектуаль конкурсларда катнаштыру; укытучыларны һәм укучыларны проект һәм тикшерү эшчәнлегенә киңрәк тартуны төп бурыч итеп куйды.

Һәр методик берләшмә үз эшен план нигезендә алып барды. Берләшмә утырышларында түбәндәге мәсьәләләр каралды:

1.Узган уку елына анализ, яңа уку елына эш планын, укытучыларның календар-тематик планнарын раслау.

2. Фән атналыкларын планлаштыру.
3. Сәләтле укучылар белән эш оештыру. Олимпиадаларның мәктәп турларын әзерләү һәм үткәрү, район, республика турларында катнашу.
4. Фәнни-тикшеренү, проект эшләре белән төрле конкурсларда катнашу.
5. Укучыларның фәнни-гамәли конференциясен үткәрү.
6. Бердәм дәүләт имтиханнарына әзерлек.

Һәр берләшмә үз эшчәнлеген аерым методик тема буенча оештырды:

| № | Методик берләшмә | Методик берләшмә проблемасы |
|---|---|---|
| 1. | Математика фәннәре укытучылары м.б. | “ Сәләтле балалар белән эшләүдә яңа технологик алымнарны куллану” |
| 2. | Гуманитар фәннәр циклы укытучылары м.б. | “Үзенең гражданлык позициясен дөрес билгели алган югары интеллектуаль үсешкә ия булган шәхес тәрбияләү” |
| 3. | Биология,химия,география фәннәре укытучылары м.б. | “ Сәләтле балалар белән эшләүдә яңа технологик алымнарны куллану” |
| 4. | Башлангыч сыйныф укытучылары м.б. | «Яңа технологияләр кулланып укучыларның иҗади сәләтләрен үстерү» |
| 5. | Сыныф җитәкчеләре м.б. | «Укучыларга физик, рухи һәм әхлак тәрбиясе бирүдә укыту-тәрбия процессының эффектлылыгын күтәрү» |

Узган уку елында һәр методик берләшмә үз алдына сәләтле укучылар белән эшчәнлекне тагын да яхшырту, аларны төрле конкурс-чараларда, интеллектуаль марафоннарда, фән олимпиадаларында күбрәк катнаштыру бурычын куйды.

Мәктәпнең методик берләшмәләре укучыларны йомгаклау аттестациясенә әзерләү буенча актив эш алып бардылар. Сынау имтиханнары һәм телдән имтиханнар өчен материаллар әзерләнде.

Коллективның һәр педагогы үз белемен күтәрү, елдан-ел камилләштерү өстендә системалы эш алып барырга тиеш. Бу юнәлештә дә укытучыларның эшчәнлеге планлы рәвештә алып барыла. Һәр укытучы үз белемен күтәрү планы буенча максатчан эшли, белем күтәрү курсларында була. Узган уку елы дәвамында 3 укытучы белем күтәрү курсларында булды, 3 укытучы переквалификация курсларын үттеләр. Башлангыч сыйныфларда эшләүче барлык педагоглар да ФГОС буенча курслар үттеләр.

2015 -2016 нчы уку елында Мораса урта гомуми белем мәктәбендә барлыгы 18 педагог эшләде. Укытучыларның барысы да үз квалификациясе буенча эшли. Шулар арасында бу уку елында 2 укытучы (Бурганова Г.Г., Валеев М.И.) I категорияне, 1 укытучы (Валеева Л.А.,.) үз вазифасына туры килүне раслады.

Уку елы дәвамында аттестациягә керүче укытучылар белән эш оештырылды, эксперт комиссияләргә ачык дәресләр, чаралар күрсәтелде, аларның эшчәнлеге тикшерелде һәм анализланды. Укытучылар аттестацион курсларда тиешле вакытларында белем алдылар.

## Эчке контрольгә анализ

Узган уку елында эчке контроль план нигезендә түбәндәге юнәлешләрдә алып барылды:

- педагогик кадрлар эшчәнлеге;

- укучыларның белем һәм күнекмәләре торышы;
- мәктәп документациясе белән эшчәнлекнең торышы;
- һәр балага белем алу мөмкинлекләр булдыруның үтәлеше;
- фәннәрне укытуның торышы;
- имтиханнарга әзерлек эшчәнлеге.

Фәннәрне укытуның торышын өйрәнгәндә, методик берләшмәләр һәм администрация тарафыннан дәресне оештыруның форма һәм методларын камилләштерү һәм дифференциальләштерүгә аерым игътибар бирелде.

1,4,5,10,9,11 сыйныфларда гомуми-сыйныф контроле үткәрелде.

6,7,8 сыйныфларда яңа өйрәнә башлаган фәннәрне укытуның торышы тикшерелде. Укытучыларга дәреснең форма һәм методларын камилләштерү; укучыларның мөстәкыйль эшләрен оештыру; дәрескә куелган максатларның үтәлеше; предметара бәйләнеш; дәресләрнең фәннилеге, аңлаешлылыгы, тормыш белән бәйләнеше, системалылыгы һәм эзлеклелеге; дәресне оештыру һәм үткәрү буенча методик, практик һәм психологик ярдәм күрсәтелде.

Каралган һәм анализланган дәресләр буенча нәтиҗә:
- укытучылар укыту материалларын яхшы беләләр;
- барлык укытучылар да дәресләрдә алдынгы технологияләр, компьютер технологияләре кулланалар;
- укытучылар дәресләрдә, өйгә эшләр биргәндә төрле дәрәҗәдә үзләштерүче укучыларның мөмкинлекләрен исәпкә алып эшлиләр;
- укытучылар укучыларның шәхси сыйфатларын үстерүне (фикерләү, сөйләм, ихтыяр көче, әхлаклелек, аралашу культурасы) максат итеп куялар, тормышка ашыралар.
Укучылар дәрестә актив, оешкан; белем дәрәҗәләре уртача. Һәр класста фәннәрне үзләштерү дәрәҗәсе түбән булган 1-2 укучы бар.

Укучыларның белем һәм күнекмәләрен тикшерү өчен төп предметлардан ел дәвамында административ контроль эшләр алынды. Контроль эш нәтиҗәләрен анализлаганда, чирек билгеләренең административ контроль эш нәтиҗәләреннән югары булуы күзәтелә.

Уку елы дәвамында укытучыларның мәктәп документациясе (класс журналлары, шәхси делолар) белән эшчәнлеге контрольга алынды. Укучыларның контроль, язма, практик эшләр дәфтәрләре, көндәлекләре тикшерелде.

Укучыларның көндәлекләрен тикшерү нәтиҗәләреннән күренгәнчә, көндәлек тотышына игътибарны нык арттырырга кирәк. Укытучыларның кайберләре көндәлеккә билге куюны кирәк санамый. Укучыларның көндәлекләре чиста, пөхтә түгел. Шул ук күренеш укучыларның эш дәфтәрләрендә дә күзәтелә. Укучыларның каллиграфиясе начар, хаталар өстендә эш системалы алып барылса да, контроль эшләрдә шул ук типтагы хаталар кабатлана.

Авылда булган һәр баланы мәктәптә укыту, аларга белем алу өчен шартлар тудыру да ел дәвамында контрольдә булды. План нигезендә укучыларның дәрескә йөреше, авыр

үзләштерүчеләр белән эшчәнлекнең торышы, өйгә эшләр бирүнең күләме тикшерелде һәм директор алды, завуч алды киңәшмәләрендә анализланды.

Имтиханнарга әзерлекнең торышы даими рәвештә контрольдә тотылды. Кабинетларда имтиханнарга әзерлек буенча стендлар вакытында ясалды, имтихан материаллары әзерләнде, консультацияләр үткәрелде.

Нәтиҗәләр:

1. МБ утырышларының тематикасы МБ алдында торучы төп проблемалы сорауларны чагылдыра.
2.Утырышлар җентекләп әзерләнгән һәм уйланган. Чыгышлар һәм нәтиҗәләр тирән анализга, фәнни-методик гомумиләштерүләр ясарга ярдәм итүче практик нәтиҗәләргә нигезләнгән.
3. Сайлап алынган чаралар комплексы фәнни-методик бурычлар системасын минималь күләмдә чишәргә ярдәм итә.
4. Контрольнең төп юнәлешләре һәм дәресләргә йөру тематикасы дөрес сайланган. Бу укыту сыйфатын, дәрес структурасын, дәрестә кулланыла торган метод һәм формаларны сайлап алуны яхшыртуга ярдәм итә.
5. Хаталарны төзәтү һәм коррекцияләү буенча тәкъдимнәр оператив киңәшмәләрдә, методик совет, методик берләшмәләр утырышларында, директор алды киңәшмәләрендә бирелә.

Тәкъдимнәр:

1. МБ эшчәнлегенең нигезе итеп, уку материалының төп темалары буенча предметара бәйләнешне алырга.
2. Төп игътибарны дәрес оештыруның формаларын һәм методларын камилләштерүгә юнәлтергә.
3. Алдынгы тәҗрибәне үзләштерү, гомумиләштерү һәм үз эшчәнлегенә кертү өстендә эш алып барырга.
4. МБ рамкаларында семинар – практикумнар ешрак үткәрергә.
5. Дәрескә әзерләнү һәм дәресне үткәрү барышында планлаштыруга һәм реализацияләүгә аерым игътибар бирергә.
6. Үзара дәресләргә йөрешне укытучыларның индивидуаль ихтыяҗларыннан чыгып планлаштырырга.

## 2016-2017 нчы уку елында тәрбия эшенә анализ

Укыту процессы белән беррәттән , дәрестә һәм дәрестән тыш чараларда әхлак, рухи һәм физик тәрбияне үстерү, сәләтле балалар белән эш алымнарын камилләштерү проблемасы тормышка ашыруга юнәлдерелгән күпкырлы тәрбияви эшчәнлек алып барылды.

Югары әхлакый сыйфатларга ия булган шәхес тәрбияләүдә, тәрбиянең күпкырлы булуы зур роль уйный. Безнең гомумбелем бирү мәктәбендә дә төрле яклап бала психикасын киләчәк тормыш өчен әзерләүне максат итеп куйган чаралар уздыру күздә тотыла. Шуңа бәйле рәвештә ел башында ук тәрбиянең төрле өлкәләре буенча җентекләп план төзелә. Яңа уку елы башлану белән сыйныфларда эш бүленеше каралып, үзидарә эшен башлап җибәрде. “ Форпост” оешмасына укучылар сайланып куелды.

Узган уку елында эчке контроль план нигезендә түбәндәге юнәлешләрдә алып барылды:

- педагогик кадрлар эшчәнлеге;

- укучыларның белем һәм күнекмәләре торышы;

- мәктәп документациясе белән эшчәнлекнең торышы;

- һәр балага белем алу мөмкинлекләр булдыруның үтәлеше;

- фәннәрне укытуның торышы;

- имтиханнарга әзерлек эшчәнлеге.

Мәктәптә тәрбия системасы укучыларда аларның һәрьялап үсешенә алшарт булырлык сыйфатлар, рухи кыйммәтләр, принциплар формалаштыру, укучыларны җәмгыять тормышына әзерләү максатын тормышка ашыруны күздә тотып төзелгән.

2016-2017 нче уку елында педагогик коллектив алдына түбәндәге бурычлар куелды:

- бала шәхесен өйрәнү, сәләтләрен ачу,кызыксынуларын анализлау;

- балалар оешмасы, укучылар үзидарәсе эшен киң җәелдерү, гражданлык активлыгын үстерү;

- укучыларның гаиләләре белән тыгыз элемтәдә тору,индивидуаль эш;

- хокук бозуларны профилактикалау,спорт һәм сәламәт тормыш рәвешен пропагандалау.

Тәрбия эшчәнлеген оештыруда 10 класс җитәкчесе, 1 педагог оештыручы катнашты. Классы булмаган фән укытучылары да тәрбия чаралары оештыруга тартылды.

«Путь к успеху» наркоманияне профилактикалау программасы буенча эш бара, ләкин канәгатьләнерлек түгел. Бу уку елында һәр класс җитәкчесенә бу программа буенча эшләргә, ата-аналар җыелышларының бер өлешен программада бирелгән темаларга багышларга.

Класс җитәкчеләре, тәрбиячеләрнең тәрбия планнары шушы программаларны тормышка ашыру максатында төзелгән. Укучыларның яшь үзенчәлекләренә туры килгән форма һәм темалар сайланган. Тәрбиягә авыр бирелүче, аларның әти-әниләре белән индивидуаль эш планнары булдырып, шуның буенча эшләргә

Мәктәптә психологик климат уңай. Дәресләрдә белем бирү белән беррәттән тәрбияви кыйммәтләр дә читтә калмый. Әхлак тәрбиясе, сәламәт тормыш рәвешен пропогандалау, укучыларның уңышлы булуына алшарт булырлык рухи кыйммәтләр, принциплар формалаштыруга зур игътибар бирелә.

Мәктәптә традицион чаралар тиешле югарылыкта үтте:Белем бәйрәме, өлкәннәр көне, укытучылар көне,әниләр көне һ.б.бәйрәмнәр эчтәлекле,файдалы үтте дияргә була.

Тәрбия системасының һәр юнәлеше буенча эш барды.Экологик , патриотик тәрбия һ.б юнәлешләр буенча күп кенә конкурслар үтте Шулай ук мәктәбебездә хәтер көнен билгеләп үтү, үз халкыбызның күренекле уллары һәм кызлары булган шәхесләрне искә төшерү, аларга багышлап тәрбия сәгатьләре үткәрү, Россия һәм Татарстан Конституциясе кабул итү көннәрен, халыклар бердәмлеге көнен билгеләп үтү матур традициягә әйләнеп бара. Бу чаралар барысы да – патриотик аң, гражданлык позициясе тәрбияләүгә беренче адымнар.

Балаларның иҗади сәләтләрен ачу һәм мөстәкыйльлекләрен үстерүгә юнәлтелгән "Юлдаш"-Балалар оешмасы президенты итеп Ильина И.В сайланды.Министрлар билгеләнде.Әлеге министрлар һәр атнаның дүшәмбесендә иртәнге линейкада мәктәп укучылары каршында үз юнәлешләре буенча чыгыш ясадылар."Лидерлык нигезләре"буенча эш дәвам итә.

Тәрбия эшчәнлеген оештыру, алдынгы тәҗрибә таратуда класс җитәкчеләренең МБ роле зур. Садретдинов М.Х.. җитәкчелегендә МБ 10 укытучыны берләштерә. 2016-2017 нчы уку елында 1,3 сыйныфта сыйныф җитәкчесе- Сафиуллина Р.Р. 2,4 сыйныфта- Капитова И.Г., 5 сыйныфта-Бурганов Ф.Н. , 6 сыйныфта- Галиуллина Р.Г., 7 сыйныфта-Хуснутдинов И.М., 8 сыйныфта Валеева Л.А., 9 сыйныфта-Сафина М.М., 10 сыйныфта-Шакирова Г.Х.. 11 сыйныфта- Насибуллина Г.Р., балаларга белем һәм тәрбия бирделәр . Берләшмәдә методик эшчәнлеккә зур игътибар бирелә. Класс җитәкчеләре арасында эш стажлары күп булган сыйныф җитәкчеләре дә, әле берничә генә ел эшләүчеләре дә бар. Алар һәрвакыт ярдәмләшеп эшлиләр. Тәҗрибә уртаклашу методик берләшмә утырышларында алып барыла.

Тәрбия системасының мөһим тармакларыннан берсе укучылар үзидарәсе һәм укучылар оешмасы эшчәнлеге. 2016-2017 нчы уку елында педагог оештыручы Валеева Л.А. җитәкчелегендә "Юлдаш" укучылар оешмасы түбәндәге юнәлешләр буенча эшләде:

- хезмәт юнәлеше ( миләш-балан җыю, биләмәләрне тәртиптә тоту)

- кайгырту юнәлеше ( мәктәпкүләм игелекле эшләр башкару; тимурчылык эше, өлкәннәргә шефлык)

- иҗадилык юнәлеше ( конкурсларда катнашу, мәктәптә төрле кичәләр, бәйрәмнәр уздыру)

- лидерлык юнәлеше (укучылар үзидарәсе эшчәнлеге, класс активларының эшчәнлеге, анкеталар алу, сайлаулар уздыру, вожатыйлар эшчәнлеге).

Бу уку елында оешма эшчәнлегенең уңай яклары түбәндәгеләр:

1. Класс старосталарының эше активлашты. Утырышлары узды, беркетмә дәфтәрләре алып барылды, һәр чарага зур җаваплылык белән әзерләнделәр. Ләкин башка активлар эшчәнлегенә игътибарны әле арттырасы бар.

2. Укучылар үзидарәсе «ФОРПОСТ» һәм «Профилактика отряды» белән берлектә эшләделәр. Мәктәпкүләм бәйрәмнәрне уздыруга ярдәм итүгә, игелекле эшләр башкаруда бергә һәм актив катнаштылар.

3. Мәктәптә министрлыклар һәр шимбә саен класслардан отчет алып, линейкаларда чыгыш ясадылар, бу аларның мөстәкыйльлекләрен арттыруга ярдәм итә.

4. Үзидарә укучылары белән берлектә мәктәпкүләм бәйрәмнәр ( Укытучылар көне, әниләр көне, Яңа ел, 23 февраль, 8 март һ.б.) уздырдылар, бу эшкә башка укучыларны да тарттылар. Бу исә укучылар үзидарәсенең елдан-ел камилләшә баруын раслый.

Укучылар үзидарәсе белән эшчәнлектә түбәндәге кимчелекләрне төзәтәсе бар:

- класс, үзидарә утырыш беркетмәләре, документация белән эшкә игътибар җитми.

- Укучыларның тәрбиялелек дәрәҗәсе уртачадан югары. Шулай да укучыларның үз-үзләрен тоту кагыйдәләрен, этикет кагыйдәләрен төшендерүгә игътибарны арттырырга кирәклеге ачык күренә.

-Укучылар арасында җинаять эшләре булганы юк, хокук бозулар күзәтелми. Хокук бозган өчен балигъ булмаган яшьләр белән эшләү инспекциясендә учётта торучылар юк.

Хокук бозуларны профилактикалау буенча системалы эш алып барылды. Укучылар арасында хокук бозуларны кисәтү максатыннан күп чаралар узды. ГИБДД һәм балигъ булмаган яшьләр белән эшләү инспекциясе хезмәткәрләре белән очрашулар , яшүсмерләрнең бурычлары һәм хокуклары турында сөйләшүләр. Быелгы уку елында да тәрбиягә авыр бирелүче балалар белән эшләү планы төзелде. Шулай да бар да яхшы дип булмый, профилактика буенча укучылар һәм әти-әниләр белән эшчәнлекне көчәйтергә, тренинглар уздырырга, укучыларыбызга якынрак булырга кирәк.

Спорт һәм сәламәтләндеру эшенең торышы уртача. Медицина күзәтүләренең чагыштырма анализыннан чыгып нәтиҗә ясаганда, мәктәптә сколиоз, нарушение осанки, миопия, кариес авыруларының артуы күзәтелә. Безгә бу юнәлештә кичекмәстән эшчәнлекне көчәйтергә кирәклеген күрсәтә.

Район күләмендә спорт ярышларында даими катнашып киләбез. Кул көрәше, татар көрәше, шахмат буенча укучылар ярышларда катнашып, яхшы нәтиҗәләргә ирештеләр.Укучыларны спортка киңрәк тарту максатында массакүләм спорт чаралары уздыруны һаман гамәлгә кертеп җибәрә алмыйбыз. Алдагы уку елында укучыларны спорт ярышларында команда белән катнашуга киңрәк тарту өчен массакүләм спорт чаралары уздыруны бурыч итеп куябыз. Укучылар, укытучылар һәм әти-әниләр арасында сәламәт тормыш рәвешен пропагандалау эшен көчәйтергә.

Укучыларның буш вакытларын файдалы уздыру өчен шартлар тудырылган. Мәктәбебездә 2016-2017 нчы уку елында 7 түгәрәк эшләде: Уку елы башында укучыларның түгәрәкләргә йөреше турында информация алынган иде. Укучыларыбыз уку белән беррәттән төрле конкурсларда һәм төрле спорт ярышларында актив катнашырга тырыштылар һәм берникадәр матур нәтиҗәләргә ирештеләр.

Спорт буенча ирешкән нәтиҗәләр дә куандырырлык. Май аенда мәктәптә район буенча спартакида булып үтте. Спорт ярышларында укучыларыбыз бик күп призлы урыннар алып, кыйммәтле бүләкләргә лаек булдылар.

Шушы чараларда катнашу, үзеңне күрсәтә белү, куелган максатларга ирешү укучыларның социаль активлыгын арттыра, кешеләр белән аралашу культурасын үстерә, яңа дуслар табарга ярдәм итә.

Мәктәп бакчасында укучылар җәйге практика үтеп хезмәт тәрбиясе алды.1 сыйныфлардан кала, калган  балалар мәктәп яны тәҗрибә участогында практикаларын билгеләнгән срокта үтеп беттеләр.

Мәктәп җирлекнең социаль-культура үзәге булып тора. Алан авылы җирлегендә мәдәни чаралар, җәмәгатьчелек белән эш, нигездә, укытучылар коллективы көче белән башкарыла.

Анализдан күренгәнчә, алдагы уку елында тәртип бозуларны һәм наркоманияне профилактикалау максатында әти-әниләр белән «Путь к успеху» программасы буенча эшчәнлекне көчәйтергә; укучылар, укытучылар һәм әти-әниләргә спорт һәм сәламәт тормыш рәвешен пропагандалауны, укучыларда белем алуга уңай караш булдыруда әти-әниләр белән хезмәттәшлекне дәвам итәргә, укучыларның тәрбиялелек дәрәҗәсен үстерү юнәлешендә нәфис зәвык тәрбияләүгә комплекслы якын килергә кирәк.

**Колбай Мораса урта мәктәбенең 2016-2017 нчы уку елына "Юлдаш" укучылар үзидарәсе эшчәнлегенә анализ.**

Колбай Мораса урта мәктәбендә "Могҗиза" исемендәге укучылар оешмасы 1995 елдан матур гына эшләп килә. Мәктәпнең укучылар үзидарәсе уку елы башында укучылар коллективын ныгыту, лидерлар булдыру, укучыларда мөстәкыйльлек, иҗади активлык тәрбияләү максаты белән оеша.Укучылар үзидарәсе президенты үз эшен уңышлы алып бара.

Безнең Мораса урта мәктәбе мавыктыргыч, үзенчәлекле "Хосусыйлаштыру-эшлекле уен" дигән акция алып бара. Бу уен матур гына алып барыла.Укучылар уенда бик теләп катнашалар.Укучылар оештырган эш төрләрен бик яраталар.

Уку елы башында ук һәр сыйныфка аерым биләмә бүлеп бирелде.Укучылар үз биләмәләрен чистарту өчен өйләреннән кирәк, себерке алып киләләр,берсеннән-берсе уздырып эшлиләр, кар көриләр, себерәләр, гөлләр утырталар, китап ремонтлыйлар һ.б. бик күп өстәмә йөкләмәләр алалар.Ә инде ел азагында һәр сыйныфның эшчәнлегенә нәтиҗә ясала.

Шулай ук президент министрлар белән дә идарә итә.

Мәктәптә барлыгы 6 министр эшли. Алар: премьер-министр, мәгариф, матбугат, мәдәният, сәламәтлек, китап палатасы, шәфкатьлелек, хуҗалык эшләре, спорт, экология, тәртип саклау министрлары. Министрлар "Юлдаш" укучылар оешмасының планы буенча эшлиләр. Һәр министр үз вазыйфасын яратып башкара. Һәр атнаның дүшәмбесендә укучылар үзидарәсенең министрлар утырышы уздырыла.Утырышта министрлар атналык эшләренә отчёт бирәләр."Президент" министрлар эшенә бәя бирә.

Укучылар үзидарәсе аша мәктәп күләмендә һәм классларда дежур тору, “Иртәнге йолдыз” тапшыруы уздыру, тәртип саклау, игелекле эшләр башкару, тимурчылык эше, лидерлар белән эш, “ФОРПОСТ” рейдлары, китап (дәреслекләр), чисталык тикшерү рейдлары, укучыларның ялын оештыру (кичәләр, бәйрәмнәр), тематик конкурслар тормышка ашырыла. Гомумән, педагог-организатор бөтен эштә дә укучылар үзидарәсенә таяна.

“Иртәгесе көн тынычлык белән башлансын өчен, бүгенгесен шатлык белән тәмамла” шигаре астында эшләү дә эшчәнлегебезне файдалы һәм кызыклы итеп оештыруда алшарт булып тора.

2016-2017 нчы уку елында укучылар үзидарәсе эшчәнлеге канәгатьләнерлек. Шулай да укучылар үзләрен мәктәпнең чын хуҗалары итеп тойсын, актив, уңышлы шәхесләр формалашсын өчен бу юнәлештә эшчәнлекне җанландырырга кирәк.

## Укучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту буенча эшчәнлеккә анализ.

Укучыларның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, авыруларны профилактикалау буенча 2016-2017 нчы уку елында комплекслы чаралар уздырылды. Сентябрь аенда ашханә хезмәткәрләре һәм техник хезмәткәрләр белән санитария-гигиена таләпләре буенча укулар үткәрелде. Хезмәткәрләрнең вакытында медицина күзәтүе үтүләре контрольгә алынды. Сентябрь, октябрь, апрель айларында барлык укучыларга Манту кую юлы белән туберкулезга тикшерү уздырылды. Уку елы дәвамында ашханәгә кайтарылган продукциянең сыйфаты тикшерелеп торды. Шулай ук ашханәдә, мәктәптә, мәктәп территориясендә санитар-гигиеник нормаларның үтәлеше контрольдә тотылды. Авырып дәрес калдыру очраклары түбәндәгечә:

**2016-2017 нчы уку елында калдырган көннәр хакындагы мәгълүмат**

| Класс | Укучы саны | Калдырган дәрес | | Уртача күрсәткеч | |
|---|---|---|---|---|---|
| көн | дәрес | көн | дәрес | | |
| 1-4 | 27 | ***68*** | ***299*** | 2,4 | 10,6 |
| 5-11 | 66 | **258** | **1329** | 6,1 | 31,6 |

Нәтиҗәләрдән күренгәнчә, 1 укучы уртача 8,5көн яки 31 дәрес калдырган.

Укучылар медосмотрларны даими үтеп тора.

Ел дәвамында барлыгы 125 иньекция ясалды.

Һәр укучы антропометрия үлчәүләре узды. 5-11 класс укучыларының кан басымнары үлчәнде. Бу үлчәү нәтиҗәләре 26нчы формага теркәлде һәм нәтиҗәләр чыгарылды.

Мәктәпнең гомуми ата-аналар җыелышында Колбай Мораса авылы фельшеры Давлетбаева Рамиля «Укучыларның сәламәтлеге» темасына чыгыш ясады. Ел дәвамында укучылар өчен профилактик әңгәмәләр, сәламәт тормыш рәвешен агитацияләү эшчәнлеге алып барылды.

Медицина күзәтүләренең чагыштырма анализыннан чыгып нәтиҗә ясаганда, мәктәптә сколиоз, умырткалык баганасы үзгәрү, симерү, ашказаны һәм эчәклек авыруларының кимүе күзәтелә. Ә менә миопия , нарушение осанки узган уку елыннан бераз кимегәнлеге күзәтелә , кариес авыруларының саны арту безгә бу юнәлештә кичекмәстән эшчәнлекне көчәйтергә кирәклеген күрсәтә. Алдагы уку елында 3нче дәреснең 20 нче минутында күзләргә махсус күнегүләр ясатырга. Классларны , коридорларны җилләтүне контрольдә тотарга. Укучылар, укытучылар һәм эти-әниләр арасында сәламәт тормыш рәвешен пропагандалау эшен көчәйтергә.

## Мәктәп китапханәсе эшчәнлегенә анализ

Яшь буынны тәрбияләүдә, ныклы белем бирүдә китапханәнең роле бик зур. Китап балаларны тәрбияли, белем тупларга булыша, дөньяга карашны үзгәртә, тормышта үз урынын табарга булыша.

Мәктәбебездә быелгы уку елында 70 укучы һәм 16 педагог китапханәбезнең китап укучылары булып санала.

Китапханәдә бүгенге көндә 5604 әдәби китап 2880 дәреслек исәптә тора. Китапханәдә һәр укучының китап укуына, аларның китапханәгә йөрешләренә анализ ясап барыла.

Быелгы уку елында укучылар китапханәдән 1748 китап алган, якынча алганда бер укучы 19 китап укыган булып санала.

Чирек саен дәреслек - китаплар тикшерелеп, аларга бәя куела. Юбилярларга багышланган төрле китап кургәзмәләре янартып барыла. Яңа кайткан китаплар белән укучыларны китап күргәзмәләрне төзеп якыннан таныштырып барабыз. Балаларга китапка сак караш тәрбияләү, китап уку культурасы булдыру максаты белән ел буена төрле әңгәмәләр уздырыла. Бүгенге көндә китапханәләр, яңа технологияләрне, дөньяви мәгълумат киңлекләрен үзләштерергә ярдәм итүче белем йорты булып санала. .

Туган төбәкне өйрәнү, аның тарихы, атаклы кешеләре, халык йолалары, һөнәрчелекне торгызу, табигатькә сак караш тәрбияләү турында материалларны туплау һәм аларны пропагандалау безнең китапханә эшчәнлегендә алып барыла. Шулай ук сәламәт яшәү рәвеше, физкультура һәм спорт буенча әдәбиятны укучыларга тәкъдим итү дәвам итә.

Яшь буынга әхлак тәрбиясе бирү, наркоманияне кисәтү һәм аңа каршы көрәш мәсьәләләре буенча әдәбият, газета- журнал материаллары укучы балаларга вакытында житкерелеп барыла. Мәдәният, сәнгать, эстетика, матур әдәбият әсәрләре һәрвакыт укучыларга тәкъдим ителеп тора.

Китап укучыларыбызның төп өлешен 1-6 һәм 10-11 сыйныф укучылары тәшкил итә.

Китапханәченең төп бурычы - балалар сораган китапларны, белешмә сүзлекләрне, мәгълуматны табу өчен төп чыганакларны тиз арада табып бирү. Безнең төп бурычыбыз -

китапханәдә булган барлык китапларны саклап тоту. Таушалган, ертылган китапларны укучылар белән берлектә ремонтлап барабыз.

Шулай ук укучылар авыл китапханәсе белән дә тыгыз элемтәдә торалар. Соңгы елларда укучылар компьютер белән кызыксына башладылар, булмаган материалларны Интернет аша табып файдаланалар.

Мәктәп китапханәләре 2011 елдан яна программа белән эшли башлады, яна кайткан барлык дәреслек китапларны да ЭФУЛ прогаммасына вакытында кертеп барабыз, укучыларга житеп бетмәгән дәреслек китапларны башка авыл китапханәләреннән барып алып кайтабыз.

Егерме ел эшләү дәверендә проблемалар да юк түгел. Әдәби китаплар рус телендә елдан-ел азая бара, яңалары кайтмый дип әйтсәк тә дөрес булыр иде. Бу исә укучыларга тиешле күләмдә китап укуларына зыян китерә. Дәреслек китаплар житеп бетмәү дә безнең өчен зур проблема тудыра.

Китапханәнең төп бурычы- 100% укучыларны китапханәгә тарту, уку программасын үзләштерүдә ярдәм итү.

## Мәктәпнең материаль-техник базасын ныгыту буенча анализ

Мәктәпнең материаль-техник базасы хәзерге заман уку-укыту процессы таләпләренә нигездә җавап бирерлек. Бүгенге көндә мәктәпнең 8 уку кабинетында урнаштырылган 4 интерактив такта, 4 мультимедиа проекторы, дәресләрне һәм класстан тыш чараларны югары эффект белән үткәрергә мөмкинлек тудыралар. Уку елында барлык укытучылар алдында торган бурыч- шушы җиһазларны өйрәнү, аларны дәресләрдә урынлы һәм нәтиҗәле итеп куллану.

2017 нчы елның җәй айларында мәктәптә җиңелчә ремонт үткәрелде. Мәктәпнең һәр кабинетындагы идәннәр һәм парталар буялды. Бу эшләрне башкаруда мәктәпнең укытучылары, техник хезмәткәрләренең өлеше чиксез зур булды. Ремонтның бәясе 60 мең сумнан артыграк.

## II .

## 2017-2018 нче уку елына мәктәпнең методик темасы һәм бурычлары:

“Белем һәм тәрбия бирүнең сыйфатын күтәрүдә мәгълүмати-коммуникатив һәм югары нәтиҗәле педагогик технологияләрнең роле”

Максат: Укучыларның белем сыйфатын арттыру юлы белән конкурентлыкка сәләтле, инициативалы, иҗади шәхес тәрбияләү

Бурычлар:

1. Һәр укучының мөмкинлегеннән һәм ихтыяҗларыннан чыгып түләүсез белем алу хокукларын тормышка ашыру
2. “Дәрестән соң мәктәп” дәүләт мәгариф инициативасын гамәлгә ашыру максатыннан Федераль дәүләт стандартларын куллануны гамәлгә кертү.
3. Тормышта үз урынын таба алырлык шәхесләр тәрбияләп чыгару.
Мәктәп укучыларында ныклы танып-белү ихтыяҗларын формалаштыру.
4. Талантлы балаларның сәләтләрен үстерү өчен аларга һәртөрле ярдәм итү.
5. Педагогик кадрларга һәм идарә кадрларына яңача аттестация үткәрү эшен дәвам итү.
6. Заман таләпләренә җавап бирерлек итеп укыту кабинетларын җиһазлау.
7. Укучы шәхесен социальләштерүдә, профессия сайлауда мәктәпнең йогынтысын үстерү, ДЙАга хәзерлек эшләрен арттыру.
